Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасында куллану кәрзине турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 июнендә
кабул ителде

### 1 статья

Татарстан Республикасында халыкның төп социаль-демографик төркемнәре өчен куллану кәрзине кимендә биш елга бер мәртәбә билгеләнә.

### 2 статья

1. Татарстан Республикасында халыкның төп социаль-демографик төркемнәре өчен куллану кәрзиненә кертелә торган азык-төлек продуктлары түбәндәге составта һәм күләмнәрдә (натураль күрсәткечләрдә) билгеләнә:

| Исеме | Үлчәү берәмлеге | Куллану күләме (уртача елына бер кешегә) | | |
|---|---|---|---|---|
| | | хезмәткә сәләтле халык | пенсионерлар | балалар |
| Икмәк продуктлары (икмәк һәм, онга күчереп исәпләгәндә, макарон әйберләре, он, ярмалар, кузаклылар) | кг | 131,0 | 103,4 | 78,7 |
| Бәрәңге | кг | 87,8 | 70,0 | 81,0 |
| Яшелчә һәм карбыз-кавын | кг | 121,1 | 110,0 | 123,3 |
| Җиләк-җимешләр | кг | 60,0 | 45,0 | 118,1 |
| Шикәр һәм, шикәргә | кг | 23,8 | 21,2 | 21,8 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| күчереп исәпләгәндә, кондитер әйберләре | | | | |
| Ит продуктлары | кг | 58,5 | 54,0 | 44,2 |
| Балык продуктлары | кг | 20,0 | 17,0 | 20,1 |
| Сөт һәм, сөткә күчереп исәпләгәндә, сөт продуктлары | кг | 258,6 | 230,8 | 360,2 |
| Йомырка | данә | 210,0 | 200,0 | 201,0 |
| Үсемлек мае, маргарин һәм башка майлар | кг | 13,0 | 10,0 | 6,4 |
| Бүтән продуктлар (тоз, чәй, тәмләткечләр) | кг | 4,9 | 4,1 | 3,5. |

2. Азык-төлек булмаган товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең хакы белән азык-төлек продуктлары хакының түбәндәге нисбәте билгеләнә (процентларда):

| Исеме | Хезмәткә сәләтле халык | Пенсионерлар | Балалар |
|---|---|---|---|
| Азык-төлек булмаган товарлар | 45 | 45 | 45 |
| Хезмәт күрсәтүләр | 55 | 55 | 55. |

**3 статья**

Әлеге Закон үз көченә кергән көннән “Татарстан Республикасында куллану кәрзине турында” 2008 елның 7 августындагы 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 8 (III өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 13 июле
№ 62-ТРЗ